Мин татарча сөйләшәм!

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел,
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле матур тел

***“Мин татарча сөйләшәм” исемле конкурс акциясенең отчеты***
***Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы***
***Нурлат шәһәренең 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе***

Мәктәбебездә 21 февральдән 10 нчы апрельгә кадәр “Мин татарча сөйләшәм” акциясе игълан ителде.

Аның төп максаты :

-халыкны, бигрәк тә яшьләрне татар телендә сөйләшергә өйрәтү.

-Татарстанда яшәүче халыкларның дәүләт теле булган татар телен саклау;

- туган жир белән горурлану һәм толерантлык хисе тәрбияләү;

-укучыларны һәм акциядә катнашучыларны татарча аралашуга тарту.

“Мин татарча сөйләшәм” акциясе барышында үземнең 8а сыныфыннан гына 20-25 укучы катнашты. Һәр милләт, һәр халык өчен бәйрәм көн – Халыкара туган тел көне. Һәркем өчен дөньядагы барлык телләр арасында иң кадерлесе – тәүге кабат сөйләшә башлаган ана теле. Бу безнең балачагыбыз, гаиләбез, җәмгыятьтәге беренче тапкыр аралашкан телебез. Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә, һәркайсы мирас булып тора.

Татар теле һәм әдәбияты укытучылары җитәкчелегендә бер төркем укучылар, татар телен пропагандалау максатыннан, башлангыч сыйныф укучылары белән татарча төрле кызыклы уеннар үткәрделәр, татарча биеделәр һәм татарча җырлар да җырланды. Шәһәребезнең шикәрчеләр бистәсендә яшәүче халык белән аралаштылар. Алар анда төрле милләт вәкилләренә татар теленең байлыгын, аһәңлеген, үзенчәлекләрен тәкъдим иттеләр.

Иң кызыклы очрашу шикәрчеләр бистәсенең теш дәвалау бүлегендә үтте. Табибә - балаларны бик җылы каршы алды һәм алар белән татар телендә рәхәтләнеп сөйләште. Ике телдә аралашу укучылар өчен бик әһәмиятле булды.

Ул үзе дә безнең мәктәптә белем алган, балачагы һәм үсмер елларында шунда чыныккан, җәмәгать эшләрендә бик актив катнашкан, яхшы укыган. “Минем өчен татар теле – икенче туган телем кебек булып тора”,- дип укучыларга телләрне өйрәнергә кирәклеген тагын бер кат раслады.

Укучылар белән шәһәр урамнарына чыгып, “Ничә сүз өйрәтә аласың?” уены оештырылды. Уен барышында төрле милләт вәкилләренә 100гә якын татар сүзе өйрәтелде һәм өйрәнелгән сүзләрне кулланып, әңгәмә оештырылды.

“Туган телем” дип аталган әңгәмәдә татар теле һәм аны өйрәнү турында сораштыру чарасында 25 укучы катнашты. Сорау алу, җавап бирү нәтиҗәләре буенча укучыларга татар телен өйрәнү кыен булса да, алар кызыксынып өйрәнәләр икән.

Акцияне йомгаклау өлешендә Вәлиева Рузилә үзе иҗат иткән “Туган телем” шигырен тамашачыларга җиткерде.

Әгәр дә без татарча сөйләшүне гамәлгә кертсәк, бу акциянең төп максаты тормышка ашар дип уйлыйбыз. Һәм менә быелгы акциядә бөтен Болгар халкы гөрләп, рәхәтләнеп урамда да, эшли торган җирдә дә, гаиләдә дә татарча сөйләшергә теләде. Чөнки барыбыз да аңлыйбыз - бүгенге көндә әле татарча сөйләшүче буын бар икән, 50-100 елдан соң, "татар телендә сөйләшүче булыр микән? дигән зур сорау туа. Шуңа күрә үзебез дә даими аралашып сөйләшмәсәк, телне саклый алмаячакбыз. “Мин татарча сөйләшәм!” акциясе - ул бер тамаша гына түгел, ул бөтен җирдә һәм һәркөнне татарча сөйләшү дигән сүз.



Милләтеңне яклап бер
сүз әйтә алмасаң –
әйтмә, әмма аны
һичбер хурлама!

ALLDAY.RU


Мин татарча сөйләшәм
ТАТАР ТЕЛЕ

Чын матурлык
йөрәктә яши,
күзләрдә чагыла
һәм эшләгән
эшләрдә күренә.




9+5 = 14
15-8 = 7
8·2 = 16
8:2 = 4
АКЦИЯСЕ
бәйгесе.


ТАТАРЧА


мин татарча сөйләшәм!
Ә син татарча сөйләшәсеңме?
әйдә татарча сөйләшик!


Иң татлы тел - туган тел,
анам сөйләп торган тел.
(татар халык мәкале)
Самый красивый язык - родной язык, на котором
мать говорит.
(татарская народная пословица)
by G.Maksudi


мин татарча сөйләшәм!


НАШИ СПЕЦ
мин татарча сөйләшәм!
Ә син татарча сөйләшәсеңме?
Әйдә татарча сөйләшик!

ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ ТАРИХ ФАКУЛЬТЕТЫ
ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ



***Яшәсен татар әдәбияты,***
***Яшәсен туган тел!***
**Г. Тукай**

***КАУРЫЙ КАЛӘМ*****студентларның һәм укучыларның**
**Бөтенрәсәй (халыкара катнашу белән) иҗади эшләр конкурсы**
**АЛАБУГА 2017**

# ТУГАН ТЕЛЕМ

(шигырь)

Гомеремдә җыйдым гыйлем
Мөгаллимнәр бирде белем.
Күңелемә якын итеп
Алган сабак – Туган телем.

Син минем туган телем,
Син минем киләчәгем.
Тик синдә газиз  туган тел,
Бәхетем, киләчәгем.

Тел булганда адашмыйбыз,
Юлым туры, нурлы көнем.
Күз карасы кебек саклыйм,
Анам телен-Татар телен.

Вәлиева Рузилә
Нурлат шәһәре
3 нче урта гомуми
белем мәктәбенең
8 нче сыйныф укучысы
Җитәкче: Садыйкова З.У


МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ!
КИЛӘЧӘКНЕ ҮЗГӘРТӘМ!


Мин татарча сойләшәм!

# Туган телебезне яратыйк!

**Нурлат шәһәренең 3нче урта мәктәбе "Мин татарча сөйләшәм!" акциясенә кушылды. Анда татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән берлектә укучылар һәм өлкәннәр дә бик теләп катнаштылар.**

Акция мәктәптә ел саен 21нче февраль – Халыкара туган тел көненнән үк башланып китә һәм аның кысаларында һәр татар теле һәм әдәбияты укытучысы төрледән-төрле чаралар үткәрә. Мәсәлән, Гөлүсә Кабирова 7Б сыйныфы укучылары белән оештырган "Син татарча сөйләшәсеңме?" дигән сораштыруга 40лап кеше бик теләп кушылган, аларның һәркайсына "Мин татарча сөйләшәм" исемле сүзлек-буклетлар да тапшырганнар. Урамнарга чыгып, кибетләргә, ашханаларга, китапханәләргә кереп, "Ничә сүз өйрәтә аласың?" дигән уен да оештырганнар әле һәм аның барышында төрле милләт вәкилләренә 100гә якын сүз өйрәткәннәр.

Ә менә Роза Әбүбәкерова 7А сыйныфы укучылары белән "Мин татарча сөйләшәм!" акциясен китапханәдә, кишәфкать туташы кабинетында, кибетләрдә дәвам итеп, халыкны татар телендә сөйләшергә өндәгәннәр. Түштамгалар, сүзлекләр таратканнар һәм яшьләрнең, урта буын кешеләрнең татар теленә мөнәсәбәтләре белән кызыксынганнар. Лилия Баһаветдинова 6А сыйныф укучылары белән шәһәр урамнары, җәмәгать урыннары, банк, ашханә, кибет, даруханәләрдә шәһәрлеләр арасында үткәргән сораштыруларда да нурлатлылар татар теленә битараф түгелләрен һәм мондый чараларны үткәрүнең кирәклеген әйткәннәр. Ә менә мәктәпнең өлкән һәм башлангыч сыйныф укучылары Зәйтүнә Садыйкова җитәкчелегендә "Интеллектуаль уен"га кушылганнар. Укучылар җитәкчеләре белән берлектә сәфәрләрен шикәрчеләр бистәсенең урамнарында да дәвам иткәннәр һәм Мәскәү, Завод урамнарында төрле яшьтәге кешеләр белән татарча аралашканнар. 9А сыйныф укучылары Ләйсән Волкова белән берлектә "Татарча да яхшы бел" исемле әдәби-музыкаль кичәдә катнашканнар. Биредә төрле милләт балалары үзләренең татар телендә сөйләшү осталыгын шигырьләр, җырлар һәм әкиятләр сәхнәләштерү аша күрсәткәннәр, ә соңыннан мәктәп укучыларына "Мин татарча сөйләшәм!" акциясенең символы булган эмблемалар өләшкәннәр.



"Акция апрель урталарына кадәр дәвам итәчәк әле. Ул мәктәбебездә укучы бер баланы да, бер ата-ананы да татар теленә карата битараф калдырмас дигән теләктә калабыз. Акция көннәрендә генә түгел, һәрвакыт татар балалары үз телләрен белсеннәр, татарча матур итеп сөйләшсеннәр иде, ә моның өчен ата-аналар да үрнәк булырга тиеш. Үз туган телебезне өйрәник, яратыйк, саклыйк!" – дигән теләктә мәктәп укытучылары.

Лилия МӨБАРӘКШИНА